Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль район Советы
КАРАРЫ

13 декабрь 2018 ел № 267

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының 2016 елның 28 декабрендәге №145 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының муниципаль хезмәтләр Нигезләмәсе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәтләр турында»гы 2007 елның 2 мартындагы №25-ФЗ Федераль Законга, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге №217-ФЗ Федераль Закон, 2018 елның 13 июлендәге Татарстан Республикасы Законының №50-ТРЗ «Татарстан Республикасында гражданлык хезмәтләре турында» гы Законының 10 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» һәм муниципаль хезмәтләр турында Татарстан Республикасы Кодексына нигезләнеп

Әлмәт район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәтләр Нигезләмәсе турында»гы №145 карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының 2017 елның 30 мартындагы №166, 2017 елның 5 маендагы №178, 2017 елның 31маендагы №184, 2017 елның 25 сентябрендәге №196, 2018 елның 11 маендагы №238 карарлары белән керткән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар кушымтасында:

1.1.1. «Муниципаль хезмәтләр вазыйфасы» 2 нче бүлегендәге 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.5. Муниципаль хезмәтләр вазыйфасын башкару өчен квалификацион таләпләрнең һөнәри белемгә туры килүе, муниципаль стаж һәм белгечлек буенча эшләү, хезмәт вазыйфаларын башкару өчен тиешле белем һәм күнекмәләр булу, шулай ук, әгәр дә булган очракта, эш бирүченең карары.

Муниципаль хезмәтләр вазыйфасын башкару өчен квалификацион таләпләр Татарстан Республикасының муниципаль хезмәтләр Кодексында билгеләнгән

муниципаль хезмәт вазыйфаларына караган типовой квалификацион таләпләр нигезендәге хокукый актларга таянып билгеләнә. Хезмәт вазыйфаларын башкару өчен белем һәм күнекмәләргә тиешле таләпләр муниципаль хезмәтнең кайсы өлкәсендә эшләвенә карап вазыйфаи инструкция белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә белгечкә квалификацион таләпләр дә күрсәтелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкару өчен түбәндәге типовой квалификацион таләпләр куела:

1) һөнәри яктан: югары, баш һәм әйдәп баручы вазыйфалар өчен югары белем; өлкән һәм кече төркемдәге вазыйфалар өчен – югары яки урта һөнәри белем;

2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек буенча эш стажына:

Югары вазыйфадагы муниципаль хезмәт өчен – ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә дүрт елдан ким булмаган белгечлек буенча стаж;

баш вазыйфадагы муниципаль хезмәт өчен – бер елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә ике елдан ким булмаган белгечлек буенча стаж.

Әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркемдәге муниципаль хезмәт вазыйфалары өчен муниципаль хезмәт стажы, белгечлек буенча стаж таләп ителми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә дәүләт гражданлык хезмәтләрендә, аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәтләрдә һәм федераль дәүләт хезмәтләренең башка төрләрендә эшләүләре исәпкә алына.

Вазыйфаи инструкция нигезендә, әгәр дә белгечкә әлеге вазыйфаны башкару өчен уку кирәк булса, хезмәт стажы белем турында документ алганнан соң гына исәпләнә.

Әгәр дә вазыйфаи инструкция нигезендә муниципаль хезмәткәрдән махсус белем таләп ителмәсә, хезмәткәрнең эш дәверендә укуы хезмәт стажына исәпләнә.

Белгечлек яки магистратураны кызыл дипломга тәмамлаган белгеч өч ел эчендә, үз белгечлеге буенча муниципаль хезмәткәрләргә куелган квалификацион тәләпләргә туры килә торган эшкә урнашса, муниципаль хезмәт вазыйфалары буенча ярты ел, белгечлек буенча бер ел эш стажы таләп ителә»;

1.1.2. 7 бүлекнең 7.1 пунктының 2 пунктчасында “Муниципаль хезмәт белән бәйле тыюлар»:

а) «эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән сүзләреннән соң “алынган” дип тулыландырырга, “ Федераль законнарда каралган очраклардан тыш, оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырылган очраклар» дигән сүзләрен «Идарә итү һәм ревизия комиссиясе органнарында, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен (акционер) түләүсез нигездә тапшыру, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче дип алмаштырырга; Федераль законнарда каралган башка очракларда»;

б) «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга; 1.1.3. «Муниципаль хезмәт белән бәйле тыюлар»

7 бүлегендәге 7.1 пунктның 4-16 пунктчаларын тәңгәл рәвештә 7.1 пунктның 3-15 пунктчалары дип санарга;

1.1.4. “Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү” 10 бүлегендәге 10.6 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аттестация комиссиясе составына эш бирүченең сайлап куелган вәкиле, яисә аттестация узып кабул ителәчәк һәм муниципаль хезмәткәр эшләячәк бүлек, тармак вәкиле, шул тармакның кадрлар һәм хокук бүлекләре хезмәткәрләре, әгәр дә андый бүлек булмаганда җирле үзидарә органнарының әлеге мәсьәләләрне алып баручы вәкиле, шулай ук, персонал белешмәләрен күрсәтмичә бәйсез муниципаль хезмәт белән бәйле эксперт-белгеч буларак фән, мәгариф хезмәткәрләре керә. Бәйсез эксперт-белгечләр саны комиссия әгъзаларының дүрттән бер өлешеннән артмаска тиеш»;

1.1.5. “Кадрлар хезмәте” 18 бүлегендәге 18.2 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«18.2. Муниципаль хезмәтләр өчен кадрларны килешү нигезендә әзерләргә».

1. Җирле үзидарә органнары эшләү өчен югары квалификацияле муниципаль хезмәткәрләрне әзерләүне Россия Федерациясенең белем турындагы Законы нигезендә һәм Федераль Законның "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы нигезләмәсенә таянып килешү нигезендә әзерли ала.

2. Алга таба муниципаль хезмәтне үтү шарты белән максатчан укыту турында килешү (алга таба – максатчан укыту турында килешү) җирле үзидарә һәм гражданин арасында төзелә һәм уку тәмамланганнан соң билгеләнгән срокта җирле үзидарә органының күрсәтелгән оешмасында эшли.

3. Максатчан килешү конкурс нигезендә төзелә.

4. Конкурс җирле үзидарә органнары тарафыннан игълан ителә һәм җирле үзидарә органнарында төзелгән конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

5. Конкурс составына эш бирүченең сайлап куелган вәкиле, яисә аттестация узып кабул ителәчәк һәм муниципаль хезмәткәр эшләячәк бүлек, тармак вәкиле, шул тармакның кадрлар һәм хокук бүлекләре хезмәткәрләре, әгәр дә андый бүлек булмаганда җирле үзидарә органнарының әлеге мәсьәләләрне алып баручы вәкил, шулай ук, персональ белешмәләрен күрсәтмичә бәйсез муниципаль хезмәт белән бәйле эксперт-белгеч буларак фән, мәгариф хезмәткәрләре керә. Бәйсез эксперт-белгечләр саны комиссия әгъзаларының дүрттән бер өлешеннән артмаска тиеш.

6. Комиссия составы конкурс комиссиясенең эшенә, аның карарына тискәре этәргеч бирми, конфликт тудырмый торган итеп төзелә.

7. Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

8. Максатчан укыту килешүен төзү конкурсы турында информация конкурска кадәр бер ай алдан муниципаль хокукый актлар бирелә торган басма массакүләм мәгълүмат чараларында, информацион телекоммуникация челтәрләрендә, җирле үзидарә органнарының “Интернет” рәсми сайтларында басылырга тиеш.

9. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Нигезләмәнең 18.2 пунктның 8 бүлекчәсендә укып бетергәннән соң тәкъдим ителә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларының төркемнәре, әлеге вазыйфаларга квалификация таләпләре, Нигезләмәнең 18.2 пунктының 11 бүлекчәсе нигезендә конкурска тәкъдим ителә

тоган документлар исемлеге, кабул итү урыны һәм вакыты, конкурс үткәрүнең тәртибе, урыны, датасы һ.б. мәгълүматлар күрсәтелергә мөмкин.

10.Максатчан уку өчен гаризалар конкурсында Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм беренче тапкыр көндезге бүлектә урта һөнәри яки югары белемне Россия Федерациясе бюджет системасы исәбенә алучылар катнаша. Әлеге конурста катнашучы гражданин муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкарырга кергәндә һәм алга таба "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәтләр турында" гы Федераль Законга нисбәтле Нигезләмәнең 18.2 пункт 34 бүлекчәсендә күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш.

11. Конкурста катнашырга теләк белдергән гражданин җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхси гариза;

2) муниципаль хезмәттә эшләргә теләк белдерүченең федераль закон нигезендә расланган махсус формада кулдан язган һәм имзаланган анкетасы, фоторәсеме;

3) паспорт күчермәсе (конкурска килгәндә паспорт күрсәтелә);

4) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, яки хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документ (хезмәт юлын яңа башлаучылар искәрмә булып тора);

5) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәтләр турында" Федераль Законга нисбәтле, муниципаль хезмәт органнарында эшләргә яраклы икәнен дәлилләүче табиб белешмәсе;

6) гражданинның урта һөнәри яки югары белемне көндезге бүлектә Россия Федераль бюджеты исәбенә беренче тапкыр алуы, белем бирү программалары турында мәгълүмат (белгечлеге һәм юнәлеше күрсәтелеп), укыту планы нигезендә аттестация узуы, Устав буенча куелган таләпләрнең үтәлеше турында мәгариф оешмасыннан белешмә.

7) язма эш (әгәр дә конкурста язмача бирем булса).

12. Әлеге бүлекнең 11 пунктына нисбәтле, җирле үзидарә органнары җитәкчесенең карары белән документка теркәлгән персональ белешмәнең дөреслеге, тулылыгы тикшерелә.

13. Конкурс комиссиясенең катнашучыларга бәя бирү һәм сайлап алу утырышы әлеге бүлекнең 11 пунктына нигезләнеп, документ кабул итү тукталып, 14 көннән дә соңга калмыйча үтәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе утырышның вакыты, датасы, урыны хакында комиссия сәркатибе өч көн алдан комиссия әгъзаларына хәбәр итә. Утырышны комиссия рәисе, әгәр дә ул булмаса, урынбасары алып бара.

14. Утырышта конкурс комиссиясе әгъзаларының өчтән ике өлеше катнашса, утырыш хокукка ия дип санала.

15. Карар зур күпчелекнең ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Әгәр дә тавышлар тигез икән, рәислек итүче биргән тавыш исәбенә хәл ителә.

16. Конкурс комиссиясе катнашучыларны әлеге бүлекнең 11 пунктының 1-6 пунктчаларында күрсәтелгән документлар һәм конкурс нәтиҗәләре нигезендә бәяли. Җирле үзидарә органнары карары белән конкурс барышында аерым әңгәмә, тест яки язмача бирем була.

17. Индивидуаль әңгәмә катнашучы белән ирекле формада аның сайлаган һөнәренә бәйле юнәлештә була, комиссия әгъзалары аңа теоретик белем һәм шәхси сыйфатларны ачыклый торган сораулар бирәләр.

18. Катнашучының теоретик белемен һәм шәхси сыйфатларын бәяләү түбәндәге критерияләр белән бәяләнә:

1) теоретик белем дәрәҗәсе;

2) җавапларның логик төзелеше;

3) грамоталылыгы һәм сөйләм культурасы;

4) мәгариф оешмасындагы өлгереше, фәнни язмалары, фәнни конференцияләрдә, олимпиадаларда, мәгариф оешмалары үткәрә торган башка чараларда катнашуы;

5) һөнәри дәлилли алуы;

6) җирле үзидарә органнарында практика узуы.

19. Шәхси әңгәмә нәтиҗәләре конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

1) катнашучы теманың эчтәлеген эзлекле һәм тулы итеп ачып бирсә - өч балл;

2) катнашучы теманың эчтәлеген эзлекле һәм тулы итеп ачып, кайбер хаталар һәм төгәлсезлекләр җибәрсә - ике балл;

3) катнашучы теманың эчтәлеген эзлекле сөйли, ләкин тулы итеп ача алмый, кайбер хаталар һәм төгәлсезлекләр җибәрә - бер балл;

4) катнашучы теманың эчтәлеген ача алмый һәм хаталар, төгәлсезлекләр җибәрә – ноль балл.

20. Шәхси әңгәмә вакытында комиссия әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар кушыла.

21. Тест Россия Конституциясе, Татарстан Конституциясе, җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы, шулай ук үзе сайлаган һөнәргә бәйле Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына таянып җирле үзидарә органнары төзегән сорауларга нигезләнеп үткәрелә.

22. Тест нәтиҗәләренә бәя катнашучы тарафыннан бирелгән дөрес җаваплардан гыйбарәт.

23. Тест нәтиҗәләре буенча комиссия катнашучыларны түбәндәгечә бәяли:

1) 86 - 100 процент дөрес җавап булса – биш балл;

2) 70 – 85 процент дөрес җавап булса – дүрт балл;

3) 51 - 69 процент дөрес җавап булса – өч балл;

4) 35 - 50 процент дөрес җавап булса – ике балл;

5) 20 - 34 процент дөрес җавап булса – бер балл;

6) 20 проценттан азрак дөрес җавап булса – ноль балл;

24. Язма эш катнашучы тарафыннан конкурс комиссиясе билгеләгән темага басма рәвештә әзерләнә.

25. Язма эшнең темасы катнашучының Россия Конституциясе, Татарстан Конституциясе, җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы, шулай ук үзе сайлаган һөнәргә бәйле Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын белүен ачыклауга юнәлдерелгән була.

26. Язма эшне бәяләгәндә теманың тулы ачылышына, язу культурасына игътибар ителә.

27. Язма эш конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

1) катнашучы теманы эзлекле һәм тулы күләмдә ачса - өч балл;

2) катнашучы теманы эзлекле һәм тулы күләмдә ачса һәм кайбер төгәлсезлекләр җибәрсә - ике балл;

3) катнашучы теманы эзлекле ләкин тулы күләмдә ачмый, кайбер хаталар җибәрә - бер балл;

4) катнашучы теманы ачмаса - ноль балл.

28. Язма эшкә бәя комиссиянең барлык әгъзалары биргән баллар кушып ясала.

29. Конкурсның барлык төрләре буенча иң күп балл җыйган катнашучы җинүче дип табыла.

30. Конкурс комиссиясенең тавыш бирүе рәис һәм сәркатип кул куйган беркетмә белән теркәлә.

31. Конкурс комиссиясенең карары җиңүче белән җирле үзидарә арасында максатчан килешү төзү өчен нигез булып тора.

32 Катнашучы гражданнарга конкурс тәмамланып бер ай эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

33.Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (конкурс урынына бару һәм кайту, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану) катнашучының үз хисабыннан тотыла.

34. Максатчан уку тәмамланганнан соң мәҗбүри муниципаль хезмәт башкаруның срогы килешүдә күрсәтелә. Срок җирле үзидарә органы күрсәткән ярдәм вакытыннан азрак һәм биш елдан артыграк булырга тиеш түгел.

35. Максатчан укыту килешүендәге йөкләмәләр һәм җаваплылык Россия Федерациясе Законы нигезендә максатчан укыту килешүендә күрсәтелә.

36. Максатчан укыту килешүе гражданин белән бары тик бер тапкыр гына төзелә.

37. Максатчан укытуга юнәлдерелгән финанс чыгымнары килешү нигезендә җирле бюджет исәбенә тотыла;

1.1.6. "Муниципаль хезмәткәр җаваплылыгы» 22 бүлеге 22.6.2 пунктының «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

" Коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлеге докладларында, муниципаль хезмәткәр коррупцион хокук бозу фактын таныган, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителгән, язмача аңлатылган очракта, бары тик аның ризалыгы белән генә күрсәтелә ала (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү очракларыннан тыш);»

2. Башкарма комитетның хокукый идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң көченә керә, әлеге карарның 2019 елның 1 январендәге “Гражданнарны үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек хуҗалыгы алып бару, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 29 июлендәге №217-ФЗ

Федераль Законның 55 статьясы нигезендә үз көченә керә торган 1.1.2 пунктчасының өченче абзацыннан тыш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (И.Р. Баһманов).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин